ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 октябрь 2017 ел № 5907

Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 1 октябрендәге 5916 номерлы карары белән расланган суд тәртибендә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар (алга таба – гариза бирүчеләр), шул исәптән опекун билгеләү турында гариза биргән көнгә әлеге гражданнар даими рәвештә кимендә 10 ел бергә алар белән яшәгән, опекага алынган балигъ булган затның опекуны яки попечителе булырга теләк белдергән ата-аналары, әбиләре, бабайлары, абый-энеләре, апа-сеңелләре, балалары һәм оныклары (алга таба – опекун булырга теләк белдергән якын туганнары).»;

2) 1.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).»;

3) 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге | Гариза бирүчеләр (опекун булырга теләк белдергән якын туганнардан тыш) яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына түбәндәге документларны тапшыралар:<br>1) гариза (3 нче кушымта);<br>2) гражданны хокукка сәләтсез (хокукка сәләте чикләнгән) дип тану турында суд органының законлы көченә кергән карары;<br>3) эш урыныннан соңгы 12 ай өчен вазыйфасы һәм уртача хезмәт хакы күләме күрсәтелгән белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен-керемнәрне раслаучы башка документ (пенсионерлар өчен – пенсия таныклыгының күчермәләре, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан яки пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнан белешмә);<br>4) опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданны тикшерү нәтиҗәләре буенча сәламәтлек торышы турында медицина бәяләмәсе (бирелгән көннән башлап өч айдан да артмаган срокта гамәлдә);<br>5) балигъ булган опекага алынучының инвалидлык турында белешмәсе (билгеләнгән үрнәктәге) (булганда) һәм аны тернәкләндерүнең медицина-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан бирелгән индивидуаль программасы;<br>6) язылышу турында таныклык күчермәсе (әгәр опекун булырга теләк белдергән граждан никахта тоса);<br>7) опекун булырга теләк белдергән граждан белән бергә яшәүче гаиләнең балигъ булган әгъзаларының, 10 яшькә җиткән балаларның фикерен дә исәпкә алып, балигъ булган опекага алынган затның опекун белән бергә яшәвенә язмача ризалыгы (опекун тарафыннан балигъ булган опекага алынган затның опекун гаиләсе белән бергә яшәве турында карар кабул ителгән очракта), | РФ Граждан кодексы;<br>РФ Салым кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| | шулай ук кайда яшәүләренә карамастан, опекага алынган затның якын туганнарының (ата-анасының, кыз һәм ир туганнарының) ризалыгы (гариза рәвешендә);<br>- аерым очракларда опекага алынган затның теләге исәпкә алына (гариза рәвешендә);<br>8) опекага алынган затның мөлкәте турында (торак, автотранспорт, кыйммәтле кәгазьләр, саклык счетлары һ.б. турында) мәгълүматлар;<br>Опекун булырга теләк белдергән якын туганнар яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына түбәндәге документларны тапшыралар:<br>10) гариза (3 нче кушымта);<br>11) балигъ булган опекага алынган зат белән туганлыкны раслаучы документлар;<br>12) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә опекун булырга теләк белдергән гражданны медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча сәламәтлек торышы турында медицина бәяләмәсе;<br>14) язылышу турында таныклык күчермәсе (әгәр опекун булырга теләк белдергән якын туганы никахта торса).<br>*3 пунктчада каралган документлар алар бирелгән көннән башлап бер ел эчендә кабул ителә, 4 һәм 12 пунктчаларда каралган документлар алар бирелгән көннән башлап 3 ай эчендә. | |

4) 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы | - «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФДССУның Яр Чаллы шәһәре буенча (алга таба – ТР буенча Россия кулланучылар күзәтчелеге) шәһәр (район) филиалының торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында бәяләмәсе;<br>- эчке эшләр органнарының опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданның граждannар тормышына | 927 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге | һәм сәламәтлегенә карата аңлы рәвештә җинаять кылган өчен хөкем ителмәвен раслаучы белешмәсе;<br>- Шәһәр исәп-хисап үзәгеннән яшәү урыныы буенча шәхси финанс счеты күчермәсе;<br>- опека һәм попечительлек балигълык яшенә җитүгә бәйле билгеләнгән очракта, опекун булырга теләк белдергән якын туганның опекага алынучы белән ул 18 яшькә җиткәнчегә кадәр тиешенчә мөрәҗәгать итмәү фактлары булмау турында опека һәм попечительлек органнары бәяләмәсе. Опека һәм попечительлек органында әлеге мәгълүматлар булган очракта ведомствоара запрос җибәрелми. | |

5) 2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга дәүләт хезмәтеннән файдалану урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аларда хәрәкәтләнү).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны да истә тотып. | |

6) түбәндәге эчтәлектә 3.6 пункт өстәргә:

«3.6. Техник хаталарны төзәтү

3.6.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Бүлеккә тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге регламентка 8 нче кушымта);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза, шәхсән гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы яки КФҮ аша бирелә.

3.6.2. Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне гамәлгә ашыра, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки, техник хатаны төзәтә һәм имзалау өчен Бүлек башлыгына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза, төзәтелгән һәм имзалау өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән документ.

3.6.3. Бүлек башлыгы төзәтелгән документны карап тикшерә һәм имзалый һәм аны гариза бирүчегә бирү өчен Бүлек белгеченә җибәрә.

Башкаруның максималь срогы – бер көн.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган һәм, теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен җибәрелгән төзәтелгән документ.

3.6.4. Бүлек белгече документларны техник хаталы документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, төзәтелгән документны, имза куйдырып, шәхсән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның төп нөсхәсен Бүлеккә тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хатны гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедура теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза кергәннән соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.»;

4) кушымтада каралганча 8 нче кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 3 октябрендәге
5907 номерлы карарына
кушымта

Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы

__________________________________________
(башлыкның фамилиясе, инициаллары)

__________________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.и., туу датасы, яшәү урыны)

__________________________________________
__________________________________________
__________________________________________
__________________________________________
(өй, мобиль телефоны)

__________________________________________
(паспорт мәгълүматлары)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ____________________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)

Язылган ________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар _____________________________________________________
____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карарны җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail адресы: ___________ җибәрү юлы белән;

расланган күчермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша түбәдәге адрес буенча:

______________________________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм минем тарафтан тәкъдим ителгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә; гариза бирелгән вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм андагы мәгълүматлар дөрес.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | __________________ | ( __________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева